# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

12+

№20 (70)

20 июнь 2013 ел


## • Вакыйгалар эзеннән

**18 ИЮНЬ** көнне ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ** узды.

Көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне карый башлаганчы, И.Гафуров Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәйләнешләр институты белән Тарих институтында булачак үзгәрешләр турында мәгълүмат бирде. Контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм атналык чаралар турында Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** сөйләде. Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** Кабул итү кампаниясенә әзерлек белән таныштырды.

Утырышта шулай ук Идарә итү һәм территориаль үсеш институтының «Социаль өлкәдә сыйфат белән идарә итү» кафедрасын Инженерия институтына кушу мәсьәләсе уңай хәл ителде.

Экология һәм география институтының эшчәнлеге турында директор вазифаларын башкаручы **С.СЕЛИВАНОВСКАЯ** сөйләде. Чыгыштан күренгәнчә, институт уңай якка үзгәрешләр кичергән: уртача хезмәт хакы, фәнни мәкаләләр саны арткан.

Финанс эшләре буенча проректор **Р.МУЛЛАКАЕВА** 2013 елның 1 сентябреннән фәнни-педагогик хезмәткәрләргә хезмәт хакын түләү буенча кертеләчәк үзгәрешләр турында мәгълүмат җиткерде.

КФУ волонтерларының әзерлеге турында Социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор **А.МЕЖВЕДИЛОВ** хисап тотты. Ректор шушы ике көн эчендә КФУ волонтерларының яшәү һәм ашау проблемаларын чишү максатын куйды.

Көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең берсе булган Педагогика һәм психология институтындагы кафедраларның исемнәрен үзгәртү, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында этносәясәт һәм этносоциология; телевидение һәм телепроизводство кафедраларын ачу уңай хәл ителде.

• • • •

Шул ук көнне ректор **И.ГАФУРОВ КӨНЧЫГЫШНЫ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ ХАЛЫКАРА БАГЛАНЫШЛАР** институты һәм **ТАРИХ ИНСТИТУТЫ КОЛЛЕКТИВЫ** белән очрашты. Анда шушы ике институтны һәм ФСИнең тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеген кушу турында сүз барды. Шунысы төгәл билгеле: бу институтлар базасында яңа институт барлыкка киләчәк. Аның структурасы һәм исеме уку йортының Гыйлъми советында хәл ителәчәк. Ректор КФУда Көнчыгышны өйрәнү мәктәбенең бренды сакланып калачагына аеруча басым ясады.

• • • •

Шушы көннәрдә Суздаль шәһәрендә **ЮНИОРЛАР** арасында **ПАУЭРЛИФТИНГ БУЕНЧА ДӨНЬЯ БЕРЕНЧЕЛЕГЕ** узды. Россия җыелма командасы составында КФУның Алабуга институты студентлары да катнашты. Безнең спортчы кызларыбыз ярыштан 3 алтын һәм 5 көмеш медаль алып кайтты. Анна Филимонова бәйге барышында 3 дөнья рекорды куйды.

• • • •

17 июнь көнне КФУга РФдагы Төркмәнстан Вәкиллегенең Гадәттән тыш Тулы вәкаләтле вәкиле **БЕРДЫМУРАТ РӘҖӘПОВ** җитәкчелегендә **ДЕЛЕГАЦИЯ** килде. Очрашуда ректор И.Гафуров килгән кунакларны университет һәм аның эшчәнлеге белән таныштырды. Алга таба хезмәттәшлек җепләре урнаштыру турында сүз алып барылды.

• • • •

Күптән түгел **ТАРИХ ИНСТИТУТЫ ВӘКИЛЛӘРЕ НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕНДӘ ТАРИХИ-АРХЕОГРАФИК ЭКСПЕДИЦИЯДӘ** булып кайттылар. Ул ике арадагы хезмәттәшлекне ныгыту кысаларында бу өлкәдә яшәүче татарларның тарихи-мәдәни мирасын барлау максатыннан оештырылды.

• • • •

20 июнь көнне «Хәзерге дөньяда чит телләр: һөнәри һәм махсус максатлардан телне өйрәнүнең актуаль проблемалары» исемле **VI ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ** булды. Беренче көнне пленар утырыш һәм мастер-класслар үтте. Иртәгә, өч секциягә бүленеп, докладлар белән чыгыш ясаячаклар.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Диана Поварова фотосы

# КФУның киләчәк горурлыгы


**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гамәли коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты


18 июнь көнне иң яхшы чыгарылыш курс студентларын тәбрикләделәр. Аларга кызыл дипломны ректор Илшат Гафуров үзе тапшырды.

Мондый дәрәҗәгә ирешү өчен, «биш»легә уку гына аз. Чарада яхшы билгеләргә укып, шул ук вакытта иҗтимагый эшләрдә катнашып, активлык күрсәткән иң тырыш студентларны котладылар. «Ниһаять, зарыгып көткән көн дә җитте. Бүген биредә университетыбызның «алтын фонды» җыелган. Исемнәрегез сезне укыткан укытучылар хәтеренә уелып калачак. Сезнең чыгарылыш үзенчәлекле. Сез университетка Универсиада Казанда уздырылачагы билгеле булган вакытта укырга кердегез. Ә менә чыгарылыш бәйрәмегез Уеннарга әзерлекнең соңгы көннәренә туры килде. Университетта алган белемнәрне тормышта да файдаланырсыз, дигән өметтә калам. Күбегез әле аспирантурада да калыр һәм, бәлки, киләчәктә уку йортыбыздагы студентларга белем бирер. Һәммәгезгә сәламәтлек, бәхет һәм уңышлар юлдаш булсын», – диде **Илшат Гафуров** үз котлавында.

Юридик факультет, Филология һәм сәнгать институты, Икътисад һәм финанс институты елдагыча кызыл дипломнар саны буенча әйдәп баручылар рәтендә булды.

Быел университетны 86 яшьлек **Габдулла бабай Галиев** та тәмамлады. Ул Алабуга институтының татар һәм чагыштырма филологиясе факультетында бары тик «биш»ле билгеләренә генә укыган. Университетыбызның иң өлкән чыгарылыш курс студенты да чарада ректор кулыннан кызыл диплом алуга иреште (бу хакта тулырак алдагы санда укый аласыз).

Чыгарылыш курс студентлары, үз чиратларында, киләчәктә КФУның горурлыгы булырга сүз бирде. Аларның кайберләре чарада алган кичерешләре хакында безгә дә сөйләде.

**Иринә Мөхәммәтҗанова**, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының чыгарылыш курс студенты: «Мин әле һаман да университетны тәмамлавыма ышанып бетә алмыйм: кайчан гына беренче курска кергән идек, инде бишне тәмамлаганбыз. Мин бүген бик бәхетле. Диплом кулга килеп кергәч, күңелгә ничек рәхәт булганын сүзләр белән генә аңлатып бетереп булмый. Кызыл диплом алу өчен, иң беренче чиратта, тырышырга, бирелгән биремнәрне вакытында үтәп барырга, һәр эшкә җаваплы карарга, параларны «тозламаска», активлык күрсәтергә кирәк».

**Артур Мостафин**, Тарих институтының чыгарылыш курс студенты: «Тормышта гомер буена истә калырлык вакыйгалар була. Ректор кулыннан кызыл диплом алган мизгелне дә мин киләчәктә сагынып искә алачакмын. Ректорның җылы теләкләре, курсташларның шат йөзләре, күтәренке рух, тантаналы атмосфера – боларның һәммәсе минем күңелдә әле озак сакланачак. Кызыл диплом алу өчен, программадагы һәр фәнгә позитив яктан карарга кирәк. Балл һәм билге өчен генә уку дөрес түгел. Парага керер алдыннан үзеңә: «Мин бу лекциядән нинди файда ала алам?» – дигән сорау куярга һәм бертуктаусыз шуңа җавап эзләргә кирәк. Шул очракта барысы да килеп чыгачак».

Чарадан фоторепортажны ***vk.com/peoplekfu*** адресы белән кереп карый аласыз.

## • Абитуриентлар өчен

# Хәерле сәгатьтә! Башладык!

Бүген, ягъни 20 июньдә, КФУ кабул итү комиссиясенең call-үзәге үз эшчәнлеген башлап җибәрде: уку йорты абитуриентлардан документлар кабул итә башланды.



Алия Галимуллина фотосы

КФУ порталына кабул итү кагыйдәләре, әзерлек юнәлешләре һәм керү имтиханнары исемлеге, контроль саннар һәм белем алу бәяләре турындагы мәгълүмат эленгән иде инде. КФУда быел барлыгы 312 конкурс төркеменә кабул итү уздырылачак.

18 июньдә уңай билгеләрнең минималь чикләре һәм кабул итү расписаниеләре расланды. БДИны икенче дулкында бирүче укучылар, иҗади һәм һөнәри юнәлеш буенча кабул итү имтиханнарын бирүчеләр өчен, документларны тапшыру 5 июльдә тәгәлләнәчәк. 10 июльдә исә профильле юнәлештә өстәмә кабул итү имтиханнарын бирүче һәм шулай ук шәхсән КФУ тарафыннан уздырыла торган сынауларны узучы абитуриентлар өчен, документларны кабул итү тәмамланыр дип көтелә. Документларны кабул итүнең тулаем тәгәлләнү вакыты – 25 июль. Тулырак мәгълүматны кабул итү комиссиясенең ярдәм«кайнар линиясе»ннән: тел.: 221-33-33 һәм КФУның рәсми сайтыннан белергә була.

**• Универсиаданы каршылап**

# «Таләп ителгәннән дә күбрәк эшләдек!»

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Татарстанны гына түгел, бөтен Россияне, дөньяны кузгаткан Универсиада башлануга санаулы көннәр калып бара. Кемдер аны кызыксыну белән көтә, ә кемдер әзерлек эшләренең туеп, тизрәк үтеп китүен тели. Университетыбызның Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтында урак өстенең иң кызган чагы.

– Искәндәр Шамильевич, сез җитәкли торган институтта волонтерлар әзерләү эшчәнлеге ничегрәк бара?

– Бүгенге көндә институтыбыздан 205 волонтер сайлап алынды һәм югары дәрәҗәдә әзерләнде. Калганнарының волонтер була алмаулары гына кызганыч. Без 100 процент студентыбызны тәкъдим итәргә әзер идек. Бу дөрес тә булыр иде, чөнки ул безнең белгечлеккә туры килә. Әмма Универсиада дирекциясе безнең институттан шул сандагы волонтер белән генә чикләнергә булды. Шулай да бу калган студентларыбыз эшсез ятачак дигән сүз түгел. Волонтер булмаган һәр студент мәҗбүри рәвештә Универсиадада җанатар булачак. Алар бәйгеләргә йөрергә, билгеле бер күләмдә фото һәм видеоматериал җыярга, презентация әзерләргә тиеш булачак. Уку елы башлангач, сентябрь аенда, без махсус конференция оештырырга дигән фикергә килдек. Анда студентлар, бишәр кешедән торган төркемнәргә оешып (теләгәннәр үзләре генә дә чыгыш ясый ала), Универсиадада үзе катнашкан бәйге төре турында сөйләргә һәм презентация белән дәлилләп күрсәтергә тиеш булачак. Без моны институтның һәр студенты Универсиада рухын тойсын, дөньядагы иң югары масштаблы бәйгенең ничек оештырылуын һәм уздырылуын күрсен өчен эшлибез. Берничә елдан соң, студентларыбыз үзләре үк шундый өлкәдә эшләячәк һәм алар мондый эшчәнлекнең иң югары пилотажын ачык күзалларга тиеш.

**– Россия җыелма командасында КФУ студентлары да бар. Алар кемнәр һәм нинди спорт төрләрендә катнашачак?**



– Бүгенге көндә университеттан Россия командасы составына барлыгы 15 студент кертелде. Шуларның 12се – безнең институт вәкилләре. Минемчә, бу бик яхшы күрсәткеч һәм без алдынгы урынн арга дәгъва кыла алабыз. Олимпия чемпионнары, атказанган спорт мастерлары **Юлия Зарипова** (җиңел атлетика) һәм **Алексей Обмочаевларга** (волейбол) өметләребез зурдан. Алар универсиадада вузны узган ел тәмамлаучылар буларак катнашачак алар. Бу көннәрдә генә Россия чемпионатында баттерфляй ысулы белән 200 метр йөзү буенча җиңү яулаган беренче курс магистрыбыз, халыкара класслы спорт мастеры **Яна Мартынова**; җиңел атлетикада өч катлы сикерү буенча халыкара класслы спорт мастеры, беренче курс студенты **Руслан Самитов**; милли көрәштә 70 кг кадәр үлчәү категориясендә Россия һәм ТР йолдызы, 5 курс студенты **Илдар Гиниятуллиннар** бик өметле күренәләр. Тагын институтыбыздан халыкара класслы спорт мастерлары: 5 курс студенты **Михаил Идрисов** (җиңел атлетика), университетны узган ел тәмамлаган **Василий Копейкин** (җиңел атлетика), 3 курс студентлары **Мария Шекеровалар** (дзюдо); спорт мастерлары: 1 курс студенты **Радель Кашефразов** (җиңел атлетика), 4 курс студенты **Антонина Савельева** (өстәл теннисы), футболчы, спорт мастерына кандидат, 5 курс студенты **Максим Жестоков**, «Рубин» футбол клубының уенчысы, университетны узган ел тәмамлаган **Владимир Дядюн** Россия җыелма командасы әгъзалары булып сайландылар. Юридик факультет та ике студенты белән мактана ала: спорт мастерлары – узган ел университетны тәмамлаган **Татьяна Шутова** (җиңел атлетика) һәм 3 курс студенты **Дмитрий Хомяков** (авыр атлетика). Идарә итү һәм территориаль үсеш институтыннан фехтование буенча халыкара класслы спорт мастеры, узган ел университетны тәмамлаган **Елена Шашарина** шулай ук Россия өчен чыгыш ясаячак. Аларга өстәп, университетыбыздан тагын 8 кеше резерв составына кертелде. Россия җыелма командасына Татарстаннан 105 спортчы кабул ителде, ә барлыгы безнең командада 600дән артык кеше исәпләнә.

**– Ә укытучылар Универсиадада катнашачаклармы? Аларның эшләре нидән гыйбарәт булачак?**

– Институтның укытучылар коллективы бәйгеләрне оештыруда һәм үткәрүдә административ, беркетмә һәм судья составларында катнашачак. Бер өлеше җиңел атлетикада хөкемдар булачак, бер өлеше бүләкләү тантанасын, мандатлы комиссия, күңел ачу чараларын оештыруда ярдәм итәчәк. Укытучыларыбызның тәҗрибәсе, компетенциясе Универсиада таләпләренә тулысы белән туры килә. Шуңа күрә институтның мөмкин булган барлык ресурсларыннан файдаланырга тырышабыз һәм Татарстанда, Казанда үткәреләчәк безнең Универсиаданы яхшы итеп, иң югары дәрәҗәдә үткәрү өчен барлык көчне куячакбыз.

**– Университет тарафыннан универсиадага әзерлекне ничек бәялисез?**

– Безнең университет, беренче чиратта, Универсиадада волонтерлар әзерләү буенча квота белән катнашты. Безгә куелган таләпләрне тулысынча үтәдек. Ректор, проректор, институт директорлары һәм, гомумән, бөтен университет җитәкчелеге әлеге бәйгене тиешле югарылыкта үткәрү өчен, кулдан килгән барлык чараларны күрделәр. Без таләп ителгәннән дә күбрәк эшләдек. Алай гына да түгел, безнең ике спорт объекты – «Бустан» һәм «Мәскәү» – Универсиада объектлары исемлегендә.

**– Универсиададан ни көтәсез? Спортчыларыбызга әйтер сүзегез бармы?**

– Безнең төп максат – максималь санда медальләр алу һәм, шул рәвешле, Россия Федерациясен, Татарстанны, Казаныбызны таныту, дәрәҗәсен тагын да арттыру. Аннан да бигрәк, без студентлар алдына уку йортының брендын, данын халыкара дәрәҗәдә арттыру, алга җибәрү максатын куябыз. Аларга адым саен : «Сез үзегезнең КФУ студентлары икәнегезне һәрвакыт истә тотарга һәм һәр җиңүегезне университетыбызга багышларга тиеш! Спортсмен, җиңүче, чемпион буларак, сез КФУда формалаштыгыз!» – дип әйтәбез. Катнашучы спортсменнарыбызга уңышлар һәм бары тик җиңүләр генә телим. Потенциал бар, калганы да булыр!



Яна Мартынова



Алексей Обмочаев





Юлия Зарипова



Максим Жестоков

# Казанда Универсиада: саннар һәм фактлар

Мәгълүматны
**Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде

Казанда Универсиадага әзерлекнең соңгы мәлләре. Ярышлар башланырга санаулы көннәр калып бара. Каникуллар вакыты булуга карамастан, КФУның иске тулай торакларында яңадан студентлар шау-шуы ишетелә башлады. Алар, волонтер буларак, Универсиаданы каршыларга әзерләнә. Универсиада турында без нәрсә беләбез соң? Әлеге уеннар турындагы кайбер кызыклы саннар һәм фактларны сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәбез.

Универсиада Халыкара университет спорты федерациясе (FISU) тарафыннан 1959 елдан бирле ике ел саен уздырыла. Ярышта 17-28 яшьлек студент һәм аспирантлар катнаша.

Беренче җәйге Универсиада 1959 елның 26 август – 7 сентябрендә Италиянең Турин шәһәрендә уздырылган. Биредә 45 илдән 985 атлет катнашкан. Соңгы 10 елда Россия спортчылары тарафыннан Халыкара студент уеннарында 608 медаль яуланган.

2008 елның 31 маенда Брюссельдә Универсиада 2013нең нәкъ менә Казанда узачагы билгеле булды.

Россия буенча Универсиада 2013 Ялкыны эстафетасы Владивостокта башланып китте. Алексей Морозов, Динара Сафина, Камилла Гафурҗанова, Екатерина Гамова кебек танылган спортчылар Ялкынны Владивосток буенча йөртте.

Казан Универсиадасында 27 спорт төре буенча ярышлар уздырылачак. Казанга дөньяның170 иленнән 12000 спортчы һәм делегация әгъзалары, 100000 тирәсе турист һәм җанатар килер дип көтелә.

Универсиада 2013 эмблемасы нигезендә татар халык орнаментының бер өлешен тәшкил иткән лалә (тюльпан) чәчәге ята. Өстәвенә, чәчәкләр – җәйнең аерылгысыз атрибуты, яшьлек, бәхет-шатлык билгесе.

Универсиаданы үткәрү өчен, 64 спорт объекты файдаланылачак. Шуның 36сы махсус Универсиада өчен төзелде.

Казандагы Универсиада авылы Универсиадалар тарихында иң шәпләрдән булачак. Анда мәгълүмати һәм күңел ачу үзәге, күңегү заллары урнашкан. Торак корпусларының сыйдырышлыгы 14 500 кешене тәшкил итә.

Волонтерлар рекрутингы Казан һәм башка 30 төбәктәге волонтерлык үзәкләрендә тормышка ашырыла. Барлык волонтерлар 4 әзерлек блогы үтәчәк: гомуми, ориентацион, функциональ һәм объект тренингы.

Ярышларда Универсиада кунакларына шәһәрдә ориентацияләнергә 2000 шәһәр волонтеры ярдәм итәчәк. Универсиадага волонтерлар әзерләүдә Россиянең 30 төбәгеннән 53 югары уку йорты һәм иҗтимагый оешмаларыннан вәкилләр катнашкан.

Ярышта катнашучылар Универсиада авылының Төп ресторанында бушлай тукланачак. Волонтерларны ашату спорт объектлары янәшәсенә урнашкан «Макдоналдс» рестораннар челтәрендә оештырылачак.

Казандагы Универсиадага дөньяның төрле илләреннән 1000нән артык Массакүләм матбугат чаралары вәкиле аккредитацияләнәчәк. Универсиада 2013 журналистларының төп хезмәт урыны булып, яңа стадиондагы төп пресс-үзәк торачак. Ул 3-18 июльдә тәүлек буе эшләячәк.

Уеннар узган вакытта көн саен Универсиада мәдәни паркында халыкара танылган Cirque du Soleil чыгышлары оештырылачак.

XXVII Халыкара җәйге универсиаданың ачылу тантанасы 45000 тамашачы, 1500 артист катнашында 6 июльдә булачак.



**• Казан Универсиадасының төп талисманы –** Юни исемле ак барс малае. Барс – болгар ханнарының символы, Идел Болгарстанының төп өлешен тәшкил иткән барсил болгар кабиләсенең тотемы. Канатлы барс Татарстан республикасының милли символы булып санала. Шуңа республика гербына да бу җан иясе сурәте төшерелгән.

• Галимнәребез

# Юрист та, филолог та…

Татар телен, шул исәптән аның фонетикасын фәнни өйрәнә башлауга 235 ел тулды. Ул Сәгыйть Хәлфиннең русларга татар телен өйрәтү өчен хәзерләгән «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов…» исемле 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә басылып чыккан дәреслеге белән башланып китә.

XIX гасырга аяк баскач, татар телен русларга һәм татарлардан башка милләт вәкилләренә өйрәтүне күздә тотып, дистәләгән татар грамматикалары һәм үзөйрәткечләр дөнья күрә. Аларда, әлифба өйрәтүгә бәйле рәвештә, фонетика бүлегенә дә урын бирелә. Ләкин авторларның күбесе фонетика предметын бик примитив, чиктән тыш гадиләштереп аңлый һәм аңлата, хәтта аваз белән хәреф төшенчәләрен аерып карамаучылар да очрый. Дөреслек хакына әйтик, әлеге төшенчәнең аермасын белеп, сизеп эшитүчеләр дә булган. Бу бигрәк тә И.Гиганов, Г.Фәезханов, К.Насыйри хезмәтләрендә ачык күренә.



XX йөзгә кергәч, татар фонетикасы зур үсеш кичерә. Мәсәлән, татар теленең аваз составын, авазларның төзелешен, үзгәрешләрн өйрәнүгә багышланган йөзләрчә мәкаләләр, дәреслекләр һәм зур күләмле монографик хезмәтләр нәшер ителде. Шулар арасында 1910 елда «Бәянелхак» газетасы типографиясендә басылган «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» исемле китап аерым игътибарга лаек. Чөнки ул, яңа гасырга аяк баскач, татар телен өйрәнүгә багышланган беренче фәнни хезмәт булган. Аның авторы – Шәехгаттар Иманаев. Галим бу хезмәтенә зур өметләр баглаган, аның телчеләр һәм зыялылар тарафыннан танылуын теләгән. Ләкин авторны куандырырга, шатландырырга ашкынып торучылар гына табылмаган, китап басылып, шактый гомер узганнан соң гына күренекле рус галиме, танылган Шәрык телләре белгече Н.Ф.Катановның зур бәясен алган. Ни кызганыч, татар тел белгечләре һәм зыялылары аны автор үзе исән вакытта да, үлгәннән соң да күрмәгәннәр, китап уңай яктан да, кире яктан да үз бәясен алмаган, әйтерсең, андый хезмәт язылмаган да, басылып та чыкмаган. Ул хәтта 1910 елдан соң матбугатта басылган һәр язмага, һәр дәреслеккә һәм китапка үз фикерен әйтеп, үз бәясен биреп барган Г.Ибраһимов игътибарыннан да читтә калган. Китап күләме белән зур түгел, нибарысы 102 бит. Ул керештән (мөкаддимә) һәм өч бүлектән (фонетика, морфология, синтаксис) тора.

Шәехгаттар Хәсән улы Иманаев (1875-1939) – тел галиме, хокук белгече, Казан университетының Хокук җәмгыяте әгъзасы. Ул «Хокук вә хәят» журналы нәшире һәм мөхәррире (1913-1914), «Бәянелхак» газетасы мөхәррире булып эшләгән. Аның хезмәтләре Шәригать кагыйдәләрен иҗтимагый гражданлык хокукы буларак өйрәнүгә, татар фонетикасын фәнни нигезләүгә багышланган.

Исмәгыйль Рәми белән Рәис Даутов төзегән «Әдәби сүзлек»тә (2001) аньң турында түбәндәге мәгълүмат кителә: «Иманаев Шәехгаттар Хәсән улы – юрист, филолог, җәмәгать эшлеклесе. Элекке Вятка губернасы, Алабуга өязе Тирсә авылында ахун гаиләсендә туа. Башта Уфа гимназиясендә, аннан Казан гимназиясендә укый. 1891 елда Казан университетының юридик факультетына кереп, аны 1897 елда тәмамлый. 1901-1902елларда университетның тарих-филология факультетында да белем ала. Озак еллар Казанда шәһәр судьясы булып эшли, коллежский асессор чинында отставкага чыга. 1911 елны дәгъва вәкиле (адвокат) хокукы ала. 1913-1914 елларда «Хокук вә хәят» исемле журнал чыгара. Ш.Иманаев – «Бәянелхак» газетасының соңгы редакторы».

Боларга өстәп, тагын шуларны әйтергә мөмкин. Шәхес культы шаукымы Ш.Иманаевны да читләтеп үтмәгән. 1933 елда аны кулга алалар һәм, ике ел дәвам иткән тикшерүләрдән соң, Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясенең актив әгъзасы булуда һәм шул контрреволюцион оешманың Казандагы филиалын җитәкләүдә гаепләп, 1935 елда өч елга Себергә сөргенгә сөрәләр. Срогын тутырып, Казанга кайткач та, аның тормышы җайланмый, өстеннән яла ягулар дәвам итә.

Ш.Иманаев 1939 елда 64 яшендә Казанда вафат була. Үлгәннән соң 59 ел үткәч, 1998 елның 21 октябрендә, РФ Законы нигезендә Татарстан Республикасы прокуратурасы карары белән аклана.

*Мәгълүмат «Мәшһүр татар галимнәре» китабыннан алынды*

• Хәйрия эше

## Аклыкка илтсен юллар




18 июнь көнне «Мизгел» яшьләр театры һәм җырчы Ильяс Халиков Ак Барс Яшьләр үзәгендә Хәйрия концерты уздырды.

Чараны оештыруның максаты 2 яшьлек **Камил Алимовка** ярдәм итү иде. Табиблар сабыйга бик куркыныч диагноз куялар, аны дәвалау өчен бик зур суммада акча кирәк. Камилнең бик тә яшисе, башка балалар кебек уйныйсы, шаярасы, үсәсе килә. Табиблар әйтүенчә, сабыйның терелергә мөмкинлеге бар, ләкин бик нык ярдәм итәргә һәм ышанырга кирәк.

Концертка күңелләре изгелектә, гамәлләре башкаларга ярдәм итүгә корылган бик күп яшьләр килгән иде. Үгет-нәсыйхәткә корылган дини тематикалы җырлар театральләштерелгән тамаша белән үрелеп барды.

«Тамчыдан күл җыела», – дип юкка гына әйтмиләр. Күңелләребез һәрчак изгелектә булсын иде. Үзебезне авыр хәлдә калган кешеләр урынына куеп карарга өйрәник.

***P.S.*** Камил Алимовка ярдәм итәргә теләсәгез, менә бу ссылка *vk.com/club52067643* буенча үтеп, тулырак мәгълүмат карый аласыз.

• Сәяхәттән кайткач

# Себердә кунакта!

Татар филологиясе бүлегенең
**II КУРС СТУДЕНТЛАРЫ**

Имтиханнар бетеп, җәйге эссе көннәр, зарыгып көткән каникуллар башлануына карамастан, Казан федераль университеты Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге әле һаман да фән казанында кайный. Күптән түгел без, икенче курс студентлары, күренекле галим Йосыпов Фәрит Йосыф улы җитәкчелегендә озын юлга чыгып киткән идек. Экспедициядә шулай ук бүлек укытучылары Гомәров Илһам Госман улы, Хисамов Олег Ришат улы да катнашты. Безнең максатыбыз – Новосибирск өлкәсенең Куйбышев, Чанны, Венгер, Кыштовка һ.б. районнарында бик борынгы заманнардан ук яшәп килгән, төрки телләр үсеше тарихында үзенең эзен калдырган бараба татарларының рухи мирасын өйрәнү иде.

Бу эшебезне Новосибирск өлкәсенең хөкүмәт органнары, бирәдәге татар иҗтимагый оешмалары зур игътибар белән күзәтеп барганнарын тойдык. Өлкәнең хөкүмәт җитәкчеләре, район администрацияләре, авыл халкы экспедициянең нәтиҗәле эшләве өчен уңайлы шартлар тудырырга тырыштылар.

Килгән көнебездә безне, беренче булып, өлкәнең мәгариф министрлыгы җитәкчеләре, өлкә татарларының мәдәни автономиясе активистлары кабул итте.



▪ *Новосибирск өлкәсенең мәдәният министрлыгында очрашу.*

Мәдәният министрлыгында булган очрашу ике якта да бик җылы тәэсирләр калдырды. Сүз Новосибирск өлкәсе һәм Татарстан Республикасы арасындагы мәдәни, фәнни һәм мәгърифәт өлкәсендәге хезмәттәшлек турында барды. Экспедициябезнең җитәкчесе Фәрит абый бу өлкәдә уртак эшләребезнең нәтиҗәсе турында сөйләде.

Новосибирскида булып та, шәһәрдән ерак түгел гүзәл урман аланында урнашкан Россия Академиясенең Себер филиалы Филология һәм тарих институтына кермичә китү үзе зур хата булыр иде. Себер халыклары теле бүлегендәге галимнәр филология фәннәре докторы Широбокова Наталия Николаевна, филология фәннәре кандидатлары Озонова Аяна Алексеевна, Тазронова Алена Робертовна һ.б. белән очрашу да бик җылы үтте. Фәрит Йосыповичны биредә дә үз кешесе итеп каршыладылар, үткәндә башкарылган уртак проектлар турындагы матур хатирәләрне сагынып искә алдылар, алга таба да уртак фәнни эшләр башкару мөмкинчелеге турында сөйләштеләр.

Очрашу барышында бараба халкын беренче булып дөньяга таныткан, Россия тюркология фәненә нигез салган галим – академик В.В. Радлов турында да сүз булды. Узган елда галимнең 175 еллык юбилее уңаеннан, Фәрит абый Йосыпов тарафыннан яңадан бастырып чыгарылган олы хезмәтнең («Образцы народной литературы тюркских племен...») 4 томы Новосибирск өлкәсе хөкүмәте кешеләрендә



▪ *Студентлар халык җәүһәрләрен җыя*



һәм Себер галимнәрендә бик уңай тәэсирләр уятты. Бездән тюркология фәненә бөтен гомерен багышлаган галимнең исемен тагын бер кабат мәңгеләштерү юлында башкарган хезмәтләре өчен Республикабыз һәм университетыбыз җитәкчеләренә чын күңелдән әйтелгән рәхмәтләрен җиткерүебезне үтенделәр.

Рәсми чыганакларга караганда, Новосибирск өлкәсендә 30 мең татар яшәве билгеле. Экспедициябез үз эшен өлкәнең Чанны районында урнашкан авыллардан башлап җибәрде. Беренче көннән үк авыл халкы үзенең кунакчыллыгы, ачык йөзе, гадилеге белән таң калдырды. Иң беренче нәүбәттә безгә Бараба халкының гореф-гадәтләре, милли ризыклары һәм, гомумән, көндәлек тормышы белән танышу мөмкинлеге туды. Һәрбер көнебез кызыклы һәм шул ук вакытта файдалы үтте. Газета укучыларыбызга күтәренке рух, әйбәт кәеф теләп, Себер якларыннан кайнар сәламнәребезне юллыйбыз. Якын киләчәктә дә хәбәрләр көтеп калыгыз.

Мөмкинлектән файдаланып, безне үз итеп, зур хөрмәт белән каршы алган Новосибирск өлкәсе Татар мәдәният үзәген җитәкләгән Тихомирова Равза Шамил кызына, Новосибирск өлкәсе Милли мәдәни мохтарият җитәкчесе Гареев Әмир Гимадислам улына, мәдәният министры Ярославцева Наталия Васильевнага, Чанны районы башлыгы Губер Виктор Ивановичка һ.б.га олы рәхмәтебезне белдерәбез.

● Аклы-каралы дөнья

# Кошлар очышы биеклегеннән

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

«Ә син күрдеңме «чын» Казанны?» «Әлбәттә, күрдем, мин бит монда яшим». «Юк, мин беләм, күрмәдең. Әйдә, мин сиңа аны иртәгә күрсәтәм», – дип җавап кайтарды Альберт. Шундый сүзләрне ишеткәч, кызыксынып китмичә булмый. Ничек инде мин Казанны күрмәдем? Башкалабызның кай өлешен күрсәтергә җыена икән бу миңа? Бу сорауларга җавап табар өчен, икенче көнне дустым белән очрашырга булдым.



### Казанны «беренче» күрүем

Сәгать 12... Мин башкалабызның үзәк урамнарының берсендә дустымны көтәм. Башымда: «Нинди кызык әйберләр күрсәтер ул миңа? Ни өчен уңайлы кием кияргә кушты микән?» – дигән сораулар әйләнә. Шулай уйланып утырганда, яныма Альберт һәм тагын бер төркем яшьләр утыруын сизми дә калганмын. «Әйдә киттек, без сиңа чын Ирек мәйданын күрсәтәбез», – диделәр болар. Мин ризалаштым... Һәм бер 10 минуттан соң, чынлап та, Казанны элек күрмәгәнмен икән, дигән фикергә ышандым. Чөнки мин башкалабызның гүзәллегенә кошлар очышы биеклегеннән сокланып карадым. Юк, парашюттан сикермәдем, ә өй түбәсендә яңа дусларым белән бергәләп чәй эчеп утырдым. Урамнар буйлап йөргәндә, без, гадәттә, ниндидер вак әйберләрне генә күрәбез. Ә түбәдән караганда, аста бер кырмыска оясы шикелле. Бөтен кеше каядыр ашыга, машиналар бөкедә тора. Боларның барысы да күп катлы биек өйләр фонында. Монда, әйе монда син шәһәрнең чын матурлыгын һәм гүзәллеген сизә башлыйсың. Ә бит бу шәһәрдә син инде күптәннән кунак түгел.

### Романтиклар өчен экстрим

Мондый үзенчәлекле күрешүдән соң, мин дустыма үземне борчыган сорауларны биреп, түбәләрдә йөрергә яратучылар турында күбрәк белергә тырыштым. Әлеге күренеш – **руфинг** икән. Ә түбәләрдә йөрергә яратучыларны – **«руферлар»** дип йөртәләр. Бу – безнең илебездә соңгы вакытта популярлашып киткән яшьләр хәрәкәте. Аңа нигез салучы – Джон Шенон. Заманында яраткан кызына ул күп этажлы йортның түбәсендә сюрприз ясаган. Һәм шуннан бирле бөтен илдәге руферлар арасында әйтем йөри: әгәр яраткан кызыңны беренче тапкыр өй түбәсендә торганда үпсәң, мәхәббәтегез озын гомерле булачак. Хәзер исә руфинг бераз үзгәрде.

Бу хәрәктнең асылы шунда: берничә кеше (гадәттә, ул бәләкәй генә төркем) җыелышып, үзләре белән фотоаппарат, теләкләре булса, чәй алалар һәм өй түбәсенә меңәләр. Анда менеп, руферлар тормыштан читләшәләр, проблемалары турында оныталар. Һәм иң кызыгы: шундый кешеләр саны елдан-ел арта икән.

Әлбәттә, биеклеккә менәргә яратучыларның үз кагыйдәләре дә бар:

- кием уңайлы булырга тиеш. Чөнки кире очракта берәр нәрсәгә эләгеп, киемне ертып, куркыныч астында калырга мөмкин.
- түбәгә берүзеңә менәргә киңәш ителми, иң яхшысы: төркемдәге кеше саны дүрттән артмасын.
- урамда яңгыр, кар, яки һава болытлы булса, түбәгә менәргә ярамый.
- руферлар – түбәдә бары тик кунаклар. Шуңа күрә өйгә зыян китермиләр, чүп калдырмыйлар. Үз-үзләрен тыныч тоталар, тавыш чыгармаска тырышалар.

Тик, кызганычка каршы, руфингның соңгы кагыйдәсен үтәмәүчеләр дә күп. Алар түбәдә үзләреннән берәр эз калдырмыйча китмиләр. Я антенналны ваталар яки чүп-чар калдыралар. Әмма әлеге күренеш руфинг хәрәкәтенә бер дә хас түгел. Гадәттә, мондый әшәкелекләрне исерек кешеләр ясый.

### Мин дә менәр идем

Дуслар белән кичергән хисләрем белән бүлешкәч, күбесе: «Нишләп миңа әйтмәдең, минем дә менәсе килә иде бит», – диделәр. «Ә нишләп менмисез соң?», – дип сорагач: «Кыюлык җитми», – дигән җавапны еш ишетергә туры килде. Ни өчен соң бездә бар әйбер кыюлыкка кайтып кала? Тормышта шул кадәр күп кызык нәрсәләр бар, ә без аларны, мөмкинлек булса да, күрмичә калабыз. Кызганыч, тормыш бер тапкыр гына бирелә бит...

● Тәңгә - мунча, җанга - юк

# Нәрсә ул – «бәхет эше»?

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Кыюлык – ярты бәхет, диләр. Чиләгенә – капкачы, дигәндәй, кыюлык белән әрсезлек һәрвакыт бергә йөри. Бүгенге көндә БДИ бирүчеләрнең дә кайберләре белем белән түгел, ә нәкъ менә кыюлык һәм әрсезлек белән сынала.



Кабатланмас серле, көтелмәгән вакыйгаларга һәм сюрпризларга бай да соң бу дөнья! Һәр кеше үз бәхетен үзе төзи. Төрле хәлләр булгалый: шатлыктан көлүләр дә, кайгыдан күз яшьләрен түгүләр дә. БДИны «бәхет эше» диючеләр аз түгел. «2»легә укучы имтиханын «5»легә, «5»легә укучы имтиханын бирә алмаган очраклар да шактый. Үзенең белеменә ышанып кергән намуслы укучыларның баллары кайвакыт куандырырлык булмый. БДИ бирү кагыйдәләре елданел катлаулана барса да, моңа җаваплы карамау аркасында, кагыйдә бозучылар балл җыю мөмкинлегеннән колак кага. Ә бүген уку йортларының кабул итү комиссияләре иң беренче чиратта БДИ нәтиҗәләренә карый. Шпаргалка белән тотылып, имтиханны киредән бирү мөмкинлегеннән мәхрүм калган укучыларны үзем дә беләм. Эшне тапшырам дигәндә генә, комиссия тарафыннан тотылып кара әле?! Үзең дә стресс хәлендә, әти-әниләр бездән күпкә катырак борчыла. Ни генә булса да, бәхет барыбызга да кирәкле вакытта елмаймый. Андый очракта әрсезрәк укучылар, әзер җавапларны интернет челтәреннән алып, бик оста гына имтиханын югары баллга биреп чыга. Кулларында җаваплар булган килеш тә кайберәүләр куркып яисә каушап эшен бозарга мөмкин.

Ләкин бу алдау һәркемгә дә файдага түгел. Тормыш БДИ белән алдауга гына корылмаган бит. Намуслы кешеләр дә югары уңышка ирешә. Киләчәгеңне өметле итәргә теләсәң, имтиханны үз башың белән биреп чыгу күпкә уңышлырак һәм нәтиҗәлерәк булыр. Кулыңда җаваплар булган очракта да, төп таяныч булып, үзеңнең белемең булсын. Иң мөһиме: үз-үзеңә ышану, белгән материалны тиешле һәм кирәкле урында дөрес куллану

Шуның белән быелга БДИ сезоны тәмамланды. Һәркем үзенә тиешле нәтиҗә ясагандыр. Хәзер инде теләгән уку йортларына керәсе калды. Анда да зачет-имтиханнар булыр, ләкин «бәхет эше», – дип кенә котылырга уйлама. Уку йортында тудырылган һәр мөмкинлектән файдаланып, белем сандыгыңны бает.

«Бармы соң ул «бәхет эше?» – диярсез. Һәммәбезгә дә кайчан да булса бәхет елмайганы бар. Аның формуласын төзү җиңел түгел. Үз-үзенә ышанган кеше барысын булдыра ала.

● Киңәш-табыш




# Әйдаман булу серләре

**Ильмира КАМАЕВА,** татар филологиясе бүлеге

Җәйне бик яратабыз инде. Җәен берәүләр елга-күлләрдә коенып, туган ягыбыз матурлыгына хозурланып, авылда үткәрсә, икенчеләр акча эшләү максаты белән төрле җиргә эшкә урнаша, өченчеләре сәяхәткә кузгала. Студент халкы җәйне бигрәк тә ярата. Чөнки җәен имтихан-сессияләр тәмамлана, том-том китаплар да укыйсы юк. Студентлар арасында җәен үзен әйдаман буларак сынап караганнар да бардыр. Кем ул әйдаман? Ул нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Бүген сүзем нәкъ шул хакта булыр.

Әйдаманны мин үзем һәрвакыт нинди дә булса яңалык уйлап табучы, гел алга омтылучы, теләсә нинди ситуациядән чыгу юлын белүче кеше дип атар идем. Иң мөһиме, ул балаларны яратырга һәм, аларның ялын кызыклы итү өчен, бар нәрсәне дә эшләргә тиеш. Син дә быелгы җәйге ялыңны балалар дөньясына багышларга телисеңме? Димәк, әлеге киңәшләр сиңа комачауламас дип уйлыйм!

☝ Балаларга һәрвакыт сүз белән тәэсир итәргә тырыш. Елмаю, дөрес интонация һәм бала күңелен аңлау могҗизалар тудырырга сәләтле икәнен онытма.

☝ Нинди генә ситуациядә дә үз-үзең булып кал. Балалар күңеленә юл ихласлык аша салына.

☝ Кеше һәрвакыт үз хаталарында өйрәнә. Шуңа күрә ялгышкан очракта үзеңне битәрләмә. Кечкенә генә уңышың булса да шатланырга өйрән.

☝ Балалар белән эшләүдән канәгатьләнү хисе алырга өйрән.
Һәр бала – аерым шәхес. Шуңа күрә һәрберсенә игътибарыңны кызганма.

☝ Дөньяга балалар күзлеге аша кара. Без – зурлар өчен катлаулы тоелган әйберләрне шулай кабул итүе җиңелрәк булачак.

☝ Һәрвакыт юмарт бул: күтәренке эмоция, көч, кечкенә генә сюрпризлар, яхшы кәеф – болар барысы да сиңа балалардан кире әйләнеп кайтачак.

Менә шундыйрак киңәшләр. Әгәр син югарыда әйтелгәннәрне үтәргә, йокысыз төннәр үткәрергә, балалар дөньясында яшәргә әзер икән, димәк, җәйге ял лагерьләре нәкъ менә сине көтә! Киттек, дустым! Тәэсирләрең белән уртаклашырга онытма!

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.